
*Бергәләп өйрәник*



# *Мин сәламәт булып үсәм*

## *Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек*

**(6-7 яшь)**

## ***Мәкальләр***

а) Саулык-сәламәтлек – зур байлык.
б) Саф һава – тәнгә дәва.
в) Сакланган – саулыкка туйган.
г) Чирнең тиюе тиз, ә китүе озак.
д) Чисталык – сәламәтлек билгесе.

## ***Табышмаклар***

а) Ипи түгел, су түгел,

Авыр түгел, аз түгел,

Ансыз яшәү мөмкин түгел.

(Һава)

б) Иртә торгач кулыңа ал,

Миннән башла эшеңне. Паста белән мин истартам

Ап-ак итеп тешеңне. (Теш щёткасы)

в) Тешләре күп – ашамый,

Минсез эшен башламый.

(Тарак)

д) Исе юк, төсе юк,

Аннан башка тормыш юк. (Су)

## **Җырлы-биюле уен «Түгәрәк алан»**

Балалар кулга-кул тотынышып түгәрәктә такмак әйтеп йөриләр.
Бу аланда чәчәкләр күп,
Кыймыйм ләкин өзәргә.
Әминә, Гөлфия,
Әйдә әле биергә.
Бу аланда чәчәкләр күп,
Без аларга тимибез.
Лилия, Гөлия,
Әйдә бергә биибез.

## **Хәрәкәтле уен**

### **Туп кайда?**

Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәккә баса-лар. Алып баручы уртада басып тора. Уйнаучылар, алып баручыга сизелмәс-лек итеп, арттан туп бирешәләр. Әгәр алып баручы тупның кемдә икәнен сизсә, аның янына килеп: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Әлеге бала, учларын өскә каратып, кулларын югары күтәрә. Әгәр аның кулында туп булса (яки ул тупны төшереп җибәрсә), уен тәмам була. Әгәр туп анда булмаса, ул кулла-рын яңадан артка куя, һәм уен дәвам итә. Туп белән 2–3 бала тотылгач, алып баручы алышына.